| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУДАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КОДАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2021 Кодаш авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, ««Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (якын туганнары, ире/хатыны, законлы вәкиле булган очракта) 2021 елның 01 февраленнән күрсәтелүче җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (якын туганнары, ире/хатыны, законлы вәкиле булмаган очракта) 2021 елның 01 февраленнән күрсәтелүче җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен расларга (2нче кушымта).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш  авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш  авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар 2021 елның 01 февраленнән үз көченә керә.

7. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Ф.М.ШАКИРОВ

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районының
Кодаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2021 № 1
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (якын туганнары, ире/хатыны, законлы вәкиле булган очракта) 2021 елның 01 февраленнән күрсәтелүче җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Хезмәт атамасы** | **Бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2751,39 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка китерү | 675,29 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2998,30 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районының
Кодаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2021 № 1
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә (якын туганнары, ире/хатыны, законлы вәкиле булмаган очракта) 2021 елның 01 февраленнән күрсәтелүче җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Хезмәт атамасы** | **Бәясе** ***(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 494,86 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2479,68 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка китерү | 608,30 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2842,14 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |